**ГЛАВА КИРБИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422626 с. Кирби,
ул. Горького, д.26а
тел: 4-38-16

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ХӘЕРБИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

422626 Хәерби авылы,
Горкий урамы, 26а нчы йорт,
тел: 4-38-16

**2025елның 14 ноябре** **6 номер**

# КАРАР

**«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Хәерби авыл җирлеге чикләрендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү турында» 2013 елның 11 октябрендәге 4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 16 сентябрендәге 1479 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2025елның 3 февралендәге 90 номерлы карары нигезендә, КАРАР ИТӘМ**:**

1. «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Хәерби авыл җирлеге чикләрендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү турында» 2013 елның 11 октябрендәге 4 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә:

1) **1 кушымтаның 3.14 пунктындагы «а» пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга**.

2) **1 Кушымтаның 3.14 пунктындагы «б» пунктчасында «шулай ук саклау өчен» сүзләреннән соң** «җиңел янып китүче һәм янучан сыеклыкларны, дары, шартлаткыч матдәләрне, пиротехник әйберләрне, янучан газлы баллоннарны, аэрозоль савыттагы товарларны, янгын куркынычы булган (янгын куркынычы булган) матдәләрне һәм материалларны, теләсә нинди класслы хәвефлелектәге калдыкларны куллану» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Хәерби авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Башлык-Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Хәерби авыл җирлеге Советы рәис** **Р.К. Зинәтуллин**